ЧАЯН

Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ НОЯБРЬ * 2024 * КАЗАН

11

ISSN 0136-7110

Герман ОГОРОДНИКОВ



– Ә БЕЗ ӘТИ-ӘНИНЕ КАРТЛАР ЙОРТЫНА БИРМӘДЕК!

10-11 нче битләрне кара.

Алмаз ХӘМЗИН

Үзгә дөнья

Берәүләр гөнаһ юарга
Мәккәгә бара.
Күпләре Кара Диңгезгә
Казна чутына –
Шуңа ул кара...

Ызгыш-талаш һәр ягында –
Гаепсез үзе.
Бу хәлне исбатлый бары
Гасырлар күзе.

Ни җитми адәм затына
Дөньяда фани?..
Дәрьялар шаулый, җир тетри,
Диңгезләр кайный.

Гөрселди туплар, ярыла,
Кырыла халык.
Торадыр Ходай күзәтеп,
Хәйраннар калып.

Утырмый кеше иманга,
Алалмый сабак.
Ничәмә-ничә кат инде
Терелдек кабат...

Чир китә, гадәт кала бит –
Нишләмәк кирәк...
Мал өчен бугаз буучы
Күп шул бигрәк...

Аллага тапшырып, Үзен
Саталар юньгә.
Үзе дә каршы килми шул
Бүгенге көндә.

Үзләре үзен хис итә
Зур патша итеп.
Инде шуңа җайладылар,
Законны китеп.

Бөтен дөньясы иманнан
Каядыр качты.
Таҗ кияргә керештеләр
Бер-берсен "манчып".

Таралды бу вирус хәтта
Вертикаль буйлап.
Аска, түбәнгә, безгә хәтле,
Кеше агулап.

Вак булса да сорыкортлар
Кесәгә керә.
Генерал чибәркәйләре күк,
Үзенә күрә.

Зарлансам да, тырышсам да
Үзгәрмәс дөнья...
Чөнки без әйткәнчә бармый
Ул туры юлда.

Игорь КИЙКО





Шомбай болай диде...

Хөрмәтле «Чаян»! Минем бер проблемам бар – берничек тә үземә эш таба алмыйм. Эш юктан түгел – вакансияләр җитәрлек! Сәбәбе шунда ки: коллективта үз урынымны таба алмыйм. Йә нәчәлникнең юньсезе туры килә, йә бергә эшләүче кешеләр гаугачыл булып чыга, йә алар белән уртак тел табып булмый... Кайда гына урнашып карамадым инде! Нишләргә дә белмим...

Р. Х.

Казан

Укучыбызга Шомбай ага үз киңәшен бирде:

– Коллектив белән уртак тел таба алмыйсыңмы? Ә син нәчәлник булып кара, ул чакта коллективка синең белән уртак тел эзләргә туры киләчәк.

Михаил МИХАЙЛОВ

Чын табигый сәләт

Хәбирнең кулына балачактан ук бернәрсә йокмый иде. Баштарак уенчыклары ватылды, үсәрәк төшкәч, бүләк итеп бирелгән фотоаппаратлар ватылды, радиоалгычлар, хәтта сәпите. Мәктәптә укыган чакта җырлаганда, аны беренче тавыш итеп тә, икенчесе буларак та кабул итмәделәр. Әйе, башка дәресләр буенча да алга китеш сизелмәде...

Тормыш башындагы авырлыкларын җиңеп, ул гуманитар институтны тәмамлады һәм өйләнде дә әле. Шуңа карамастан, төрле кыенлыклар һаман Хәбирнең артыннан ияреп барды. Тещасы белән дә аралары җайланмады. Кер үтүкли торган такта ул кагылганнан соң төзәтерлек хәлдә булмый иде. Янган электр лампочкасы да гаилә ызгышына сәбәп булды...

Берзаман кара полосалы көтелмәгән вакыйгалар акка манылды. Ишегалдына чыгып, бергә бу йортта торучы кешеләрнең, командаларга бүленеп, ярыша-ярыша домино уйнаулары шаккатырды Хәбирне. Ул карап-карап торды да кычкырып җибәрде:

– Карагыз әле, чәчәк клумбаларыбыз юк, җәяүлеләр сукмагындагы асфальт җимерелеп беткән, агач ботаклары тәрәзәләргә кадәр үсеп, пыяланы ватыр дәрәҗәгә җиткән, шуларны берәү дә кисми! Ишегалдын яктыртучы лампалар янмый, баганалары авыш! Боларны бит тәзек хәлгә китерергә кирәк!


Домино уйнап утыручылар, уйнауларыннан туктап, аптырап калдылар. Һәм араларыннан берсе:

– Хәбир, сиңа сәясәт белән шөгыльләнергә кирәк! Без сине якларбыз!

Ниһаять мин дә җәмгыятьтә үз урынымны таптым, дип уйлап куйды Хәбир күңеленнән.

Анатолий РАДИН





Виктор БОГОРАД

Гурами ТИНИКАШВИЛИ

Эт тормышы

Яныма икенче сыйныфта укучы улым килде дә:

– Эти, минем эт буласым килә! – дип әйтеп куйды.

– Буласың килсә, бул! Сиңа кем бирми? – дидем битараф кына.

– Юк, эти, мин чынлап та эт булырга телим!

– Бар, әниеңнән сора! – дидем мин.

– Әни риза! – дип шатланып килде улым.

Мин гаҗәпләнеп хатыныма карадым.

– Аларның мәктәпләрендә, – диде хатыным, – психологлар тест уздырганнар. Балалар үзләрен нинди хайванга охшаталар. Кемдер мәчегә, кемдер эткә...

– Ә Тимур әнә үзен крокодил итеп тоя! – дип кычкырды улым.

– Ата-анасына баш бәласе инде бу... – дип тирән сулап куйдым.

Бераз уйланып утырдым да, улыма мөрәҗәгать иттем:

– Ярый, димәк, син чынлап та эт булырга телисең ди. Ул чакта бу мәсьәләне җитди кабул итәргә кирәк. Кушаматың нинди булачак инде? Шарик? Актүш??

– Трезор! – дип мыгырдады улым һәм йөзенә эт битлеге киеп куйды.

– Ярый, Трезор икән, Трезор булсын. Ләкин исеңдә тот: син хәзер идәндә, ишек төбендә йоклаячаксың!

Киштәдән иске юрган төшереп, аны алгы бүлмәгә җәеп куйдым. Улым шатланып өреп куйды һәм юрганга сузылып ятты.

– Һәр иртә әниең сине йөрергә алып чыгачак! Менә сиңа муенчак белән каеш. Бүтән мәктәпкә йөрмәячәксең. Этләр кешеләр белән мәктәптә укымый.

– Ура-а-а-а! – дип кычкырды улым, тик мин аны шунда ук туктаттым:

– Шым бул! Этләр сөйләшмиләр! Син хәзер өрә, чиный һәм шыңшый гына аласың. Синең чын эт буласың киләдер бит?

– Әйе, – дип башын селкеде улым.

– Кеше сөйләмен сиңа онытырга туры киләчәк! Иртәгә әниең сине этләр мәктәбенә кучерәчәк. Анда командалар үзләштерәчәксең: утырырга, ятарга, һәм, гомумән, хуҗаңны тыңларга!

Кухняга кереп аннан ике савыт алып чыктым. Берсенә – су, икенчесенә коры азык салып куйдым.

– Менә, кара: монысы эчәргә, ә монысы ашарга. Әйе, сиңа хәзер коры азык белән генә тукланырга туры киләчәк. Шулай да, мактау йөзеннән, кайчагында сиңа кимергәннән калган сөяк ыргытачакбыз.

Улым, сәерсенеп, башта миңа, аннан соң идәндәге эт сохариена карап куйды. Шулчак кухня ягыннан тёщаның тавышы ишетелде:

– Әйдәгез ашарга! Кичке аш әзер!

Улым битлеген салып, кухняга таба юнәлде, ләкин мин аны туктаттым:

– Этләргә кухняга керергә ярамый!

– Син нәрсә, эти?

– Урыныңны бел! – дидем катгый итеп һәм җәелгән юрганга күрсәттем.

Кухня өстәлендә, хуш исләр аңкытып, котлет белән бәрәңге тора иде. Без ашарга керештек.

– Ә оньк кайда? – дип кызыксынды тёща.

– Бу көннән сезнең оныгыгыз юк! – дип кырт кистем мин. – Ул эт булырга тели! Хәзер безнең улыбыз урынына эт. Борчылмагыз, мин аның ашарына салдым инде.

Шул вакытта ишек ачылып китте һәм кухняга улыбыз килеп керде. Ул эт битлеген салды һәм безгә мөрәҗәгать итте:


– Беләсезме, мин яхшылап уйладым һәм эт булырга теләмәвемне аңладым. Мин кеше булырга телим! Эт азыгына караганда, әбинең котлетларын ашау шәбрәк! Ул коры азык коточкыч тәмсез икән!

Улым битлек белән муенчакны чүп чиләгенә ыргытты.

– Әгәр шулай икән, кулыңны ю да ашарга утыр! – дидем мин елмаеп.



Александр АЛЁШИН



Александр ШУЛЬПИНОВ









• • •

Ниһаять кешелек дөньясы һава торышы белән идарә итәргә өйрәнде: машинаны юып кына куясың, күп тә үтми, яңгыр ява башлый: үзең белән зонтик алсаң – яңгыр яумаячак; җәйге ялың суык көннәрдә уза: кышын җепшек кар ява; көзен чаңгы алып куйсаң – кыш көне кар яумый, ә машинаңның тәгәрмәчләрен кышкыга алмаштырсаң – салкын көннәрне көтеп ала алмый интегәсең, җылы була.

• • •

Бөтен ил сәяхәт кылучылары елга ике тапкыр медкомиссия үтәргә хәрби комиссариатка агылалар – һәр яз һәм көз монда күмәк сәламәтләнү могҗизасы барлыкка килә.

• • •

Берәү аптекага керә:

– Матуркай, бер литр медицина спирты бирегез әле.

– Рецептыгыз бармы соң?

– Их, рецептым булса, аны үзем ясар идем...

• • •

Ресторанда берәү кызыксына:

– Менә сезнең менюда ялкау голубцылар, монысы аңлашыла, ә менә ялкау пилмәннәр дигәнне ничек аңларга кирәк?

– Фрикаделькалы токмачлы аш ул.

• • •

– Миңа ачык кешеләр ошый!

– Ә кем соң сез?

– Хирург.

• • •

– Миңа анекдотлардагы Вовочка кызганыч.

– Нигә?

– Инде 60 ел буе мәктәпне тәмамлый алмый.

• • •

– Хатын белән ызгыш-талаш шоу-бизнес концертындагы чыгышларны хәтерләтә.

– Ничек ул алай?

– Яңа материал белән башлый да иң яхшы хитлары белән тәмамлый.

• • •

– Исеңдә тот!.. Туйдан соң аның бар белгәне: "Син шундый күңелле!" – дигәне "Кеше алдында мине оятка калдырма, клоун!"га әйләнә.

• • •

Балалар бакчасындагы белдерү. "Хөрмәтле ата-аналар! Өегезгә кайткач, балагыз монда нәрсә булганын сөйләсә, ышанмагыз! Без, үзебезнең чиратта, аның өйдә нәрсәләр күргәнен сөйләвенә ышанмаска сүз бирәбез".

Абау!

ЭЧКЕ ГАРМОНИЯ СЕРЛӘРЕ

Казанның "Сокол" футбол клубы тренер эшенә генә таянмаска булган. Футболчылар командага 300 мең сум хезмәт хакына профессиональ таролог, ягъни булачак вакыйгаларны фаразлау буенча белгеч эзлиләр. Бу белгеч аларга уенга уңай юнәлеш алу өчен кирәк. Өстәвенә, таролог уенчылар һәм тренерлар белән консультацияләр уздырырга, һәр футболчы өчен шәхси прогнозлар төзергә тиеш. Бу гамәлләрдән соң алар туп белән эш итәргә, бәлки, өйрәнмәсләр дә, ә менә эчке гармония серләренә, тәгаен, төшенәчәкләр.

СҮЗ БАЗАРЫ

Казандагы "Әкият" курчак театры Роспатентта татар әкиятләре каһарманнарының исемнәрен товар билгесе сыйфатында теркәгән компаниядән суд алды претензиясе алган. Хәзер "Су анасы" исемен файдаланган өчен театрдан 500 мең сум һәм ул сүзләр файдаланылган һәр спектакльдән 1 сум таләп итәчәкләр. Республиканың мәдәният министрлыгы бу "сүз хуҗалары" белән мөнәсәбәтләрне суд аша ачыкларга җыена. Ә Роспатент белдерүенчә, бу очрак бердәнбер түгел, һәм бу күренеш инде "патент троллингы" дигән исем алган. Ә мондый хәлләр кабатланмасын өчен, законга үзгәреш кертергә кирәк.

СҮЗ ЧЫПЧЫК ТҮГЕЛ


Казандагы торак-төзелеш кооперативларының берсендә председатель шунда яшәүче бер хатынны судка биргән. Ул үзләренең йортлары чатында нигәдер рәисне элек төрмәдә утырган, дип белдергән. Кооператив башлыгы, озак уйлап тормыйча, хокук саклау органнарына мөрәҗәгать иткәч, хатын бөтен кеше алдында председательдән гафу үтенергә тиеш дигән карар кабул иткәннәр. Суд приставлары суд карарының үтәлүен җентекләп тикшереп торганнар. Гафу үтенүнең текстын язарга ярдәм итеп, аның йорттагы белдерүләр тактасында һәм шул ук компьютер чатында барлыкка килүен контрольдә тотканнар.


ТАРИХИ ХАТА


Бөгелмәдәге туган якны өйрәнү музее директоры бинаны кагыйдәләрдән тайпылып реставрацияләгән һәм мәдәни мирас объектын бозган. Ул башта тарих-мәдәният экспертизасы белгечләреннән рөхсәт һәм проект алырга тиеш булган. Әмма бу таләпне игътибарсыз калдырып, директор бинаның баштагы кыяфәтенә зыян китергән. Хәзер аңа карата административ эш кузгатып, музейны тагын бер кат, бу юлы инде кагыйдәләргә туры китереп реставрацияләргә мәҗбүр итәчәкләр.

ДОН КИХОТ маҗаралары

Владимир СОЛДАТОВ рәсемнәре







Николай **ВОРОНЦОВ**



Хәмид **ВӘЛИДИ**

Гомер Кояшы әле...

Үз италмыйм чит-ятларның җырын,
Үз җырымны җырлап яшимен.
Сакал-мыек аккош мамыгыдай,
Җыр яраткан күңлем яшь минем.

Тулганда да туксан, кыз, – дип гыжлар
Һәм чакырып парлап биергә.
Шаян кызлар карышмаслар аңа,
Тарсынырлар: "Син карт!" – диярга.

Мәгълүм ич, халык сүзе – хаклы.
– Мәхәббәтнең, – диләр, – яше юк.
Янып сөйгән йөрәк – ялкын-учак,
Ә күзләрдә балкый нурлы ут.

– Бу бабайга нәрсә калган инде
Бию мәйданында? – димәгез.
Кабынуы мөмкин сөю уты,
Якынырак аңа килсәгез.

– Бер – яшьлектә, бер – картлыкта, – диеп,
Җырлап яши татар бабае.
Гомер Кояшы... бары икенде дә,
Ә Ахшамга вакыт бар әле!

Туктатмагыз берүк бию көен,
Мондый кичләр кабатланмый еш.
Дөрес әйткән Тукай: шагыйрь күңелендә
Яумый карлар, булмый, диеп, кыш.
...Хак сүз әйткән сөекле Апуш.

Ләбиб **ЛЕРОН**

ФЕРШТЕЙН, МЕРСИ, МАДАМ?!

Интырбию алам дисең инде син миннән, име, иптәш карисбандит?! Ал әйдә, мин бирәм рәхәтләнеп. Сүләр сүзләрем бер букча җыелды – тыңлап кара алайса. Нәрсә? Ни дисең? Үзем белән таныштырмадыммыни әле? Әчтах мин. Әчтах Мөшәрәп угылы Бөкәшин булам ягъни, кайсыдыр ки матур итеп әйткәндә. Пенсиягә чыкканыма алты гына җыл әле. Бүгенгесе көндә калабыздагы өч милли хәрәкәтнең иң актив әгъзасымын. Егерме җиде катыргы грамотам, биш калай значугым, Лилин башы төшерелгән бер хатыным... тефү, нәгәләт!.. мидәлем димәкче идем... Әйе, бакыр йөгертелгән шундый бер мидәлем бар... Җәнә дә килеп, әлеге дә баягы бер ничауа гына хатыным, ике ыздаравай малаем, дүрт шалапут оныгым бар. Катыргыларны һәм дә калайларны завудта инженер булып эшләгәндә бирделәр. Боларны сүз уңаеннан гына әйтүем. Безнең калада мине белмәгән кеше юк. Мактануым түгел. Чыны шулай. Халык мине "Нәрсәкәйдәкайчан" дип җөртә. Күпне күргәнемә, күпне белгәнемә ишарәләп, шулай яратып әйтүләре инде үзләренчә. Бу турыдагысын тәпсилләп язмасаң да җарый. Язу дигәннән, кем, иптәш карисбандит, син мин әйткән сүзләрне берүк дөрес итеп яз инде, җәме?! Ату, кайсыдыр ки кайбер сүзләрне, исем-фамилиеләрне колак шәрифем ишеткәнчә әйтә торган җүнсез кадәтем бар. Моның өчен алдан ук түбәнчелек белән гафу үтенәм. Баштук тагын шуны әйтеп куйыйм әле: сөйләгән чакта, зинһар, бүлдермә пажалысты, җәме? Килештекме?! Маладис, башлы кеше икәнлегең күренеп тора. Мин сине бүген үк, ике дә уйламыйча, Әмерикагә перзидент итеп куяр идем. Җәл, ингелизчәм бик үк әйбәт түгел. Фирштейн, мерсимадам?!





Виктор **ФЁДОРОВ**

Александр БРЮХАНОВ

Үрдәкчә уйлану

Бервакыт шактый суык иртәдә бер үрдәк сүз башлаган:

– Туйдырды мондагы яшәү, җитмәсә, озакламый кыш килер, инде үләннәр дә сулды, Көньякка очарга вакыт...

– Безгә нәрсә, көтү җый да кит, оч Көньякка... – дип җавап кайтарган аңа кемдер...

Үрдәкләр төркеме буенча әле берсенә, әле икенчесенә йөзеп, үрдәк үгетләргә керешкән.

Бер төркемдә аннан болай сораганнар:

– Ә кем җитәкче булыр?

Үрдәк башын селкеп куйган, әйтерсең лә ул үзен тәкъдим иткән...

– Ә ни өчен син? Синең моңа нинди хакың бар? Кайсы ягың белән син миннән яхшырак? – дип кәперәйгән аңа карап яшь кенә үрдәк... – Минем дә көтү башлыгы буласым килә...

– Син Көньякка бара торган юлны беләсеңме соң? Туктап ял итә торган базаларны? – дигән аңа каршы оештыручы...

– Ә мин үземә белдекле урынбасарлар алам, – дип җавап кайтарган яше...

– Алайса син нигә кирәк аларга? – дип, болар бер-берсенең каурыйларын йолкышкан, ләкин бик ныгытып түгел...

Шулчак алар янына хәйран симез ата үрдәк йөзеп килгән һәм вәкарь кыяфәт чыгарып:

– Ә без менә бөтенләйгә калабыз... – дигән.

– Ничек инде каласыз? Көчле суыклар башланыр, кар һәм боз, – дип бакылдарга гына өлгергән үрдәгебез...

– Ә нәрсә? – дип, аптырамагандай, бүлгән аны ата үрдәк. – Кешеләр бит монда көн саен безгә ипи ашаталар, ничек булса да кышларбыз.

– Без дә бераз көтәбез әле, – дип, әңгәмәгә катышкан бәбкәләре җитлекмәгән үрдәк анасы. – Вакыт бар бит әле...

Шул вакыттан соң тирә-якны шаулатып тагын берничә көн бакылдашканнар үрдәкләр, канатларын җилкегәннәр, кыйнашканнар. Озакламый очып китәчәкләрен сөйләшкәннәр, канатларын рәтләшкәннәр. Ә беркөнне иртән әллә ни зур булмаган төркем урман артына китеп югалган...

Менә бит нихәтле кеше сүзләре белән аңлату кирәк булды үрдәкләргә яшәеш һәм тормыш итү өчен үзләренә тиңдәшләрне бу рәхимсез дөньяда.

Ә сез әйтәсез: кешеләр, әйдәгез, бергә-бергә дус яшик... – дип.

Бервакытны филләр көтүе мондый фикергә килгән: бәлки, аларга җәй көннәрендә Төньякка китеп торырга дип, анда бит яшел үлән дә күбрәк. Ләкин килешә алмаганнар. Уйлагыз, әгәр килгән булсалар, нәрсә булып бетәр иде безнең якларда...



Валентин ДРУЖИНИН

ТИШЕК КӨПЧӘК

АВАРИЯЛӘР БӘЙГЕСЕ

Акрынрак йөрсәң – азрак түлисең. Бу гади юл гыйбарәсен Татарстан тизлек сөючеләре берничек тә кабул итәргә теләми. Нәтиҗәдә, республика тискәре рейтингта җиңүче булып чыкты. Без авария ясаучы йөртүчеләр һәм юл кагыйдәләрен күп тапкыр бозучылар саны буенча өченче урынга чыктык. Тикшерүләр күрсәткәнчә, ил буенча юл вакыйгаларында берничә тапкыр гаепле булып чыгучы йөртүчеләр өлеше 2,43 процент тәшкил итә. Ә республика буенча андыйларның саны – 3,7 процент. Бераз гына алдарак Чуашстан (3,9%) һәм 3,8% белән Оренбург өлкәсе бара.

Ул арада Дәүләт Думасы юл җилкуарларына чынлапябышты бугай. "Хәвефле йөртү" төшенчәсен үзгәртергә, штрафларны сизелерлек итеп арттыру, өч айга кадәр машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителү күздә тотыла. Бу чаралар "шумахер"ларга тәэсир итәрме? Монысын вакыт күрсәтер.



Валентин ДУБИНИН



Игорь КИЙКО



Сергей АНДРИАНОВ

Советлар Союзының һәм Россиянең иң күренекле, кабатланмас карикатурачы һәм китап бизәүчеләрнең берсе Герман Огородников вафат. Аның рәсемнәренә сокланып бер генә буын үсмәгәндер. Казан сәнгать училищесын тәмамлагач, Герман Иванович озак еллар «Чаян» белән хезмәттәшлек иткән. Соңрак, үтә талантлы карикатурачыны күреп алып, аны башкаладагы «Крокодил» журналына эшкә чакыралар. Ләкин рәссам үзен олы юлга чыгарган «Чаян» белән элемтәсен өзми. Ул безнең журналыбызның логотибы һәм эмблемасының авторы (тышлыкны кара). Бу карикатуралар сәхифәсендә аның төрле елларда иҗат ителгән рәсемнәрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.






Аның тарафыннан бизәлгән китапларда берничә буын үсте.



– Бөтен күргәзмәләрдә сезнең өчен дә гел берүземә тинтерәп йөрергә туры килә!




– Сәер бәндә! Кичә безнең ашханәдә ашады һәм бүген тагын килгән!









Әйтергә кирәк, Герман Огородников яңа жанр – иронияле шәһәр панорамалары авторы иде. Бу исемлеккә Мәскәү, Ленинград, Киев, Париж, Лондон керде. Казан да читтә калмады, әлбәттә.

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Сөйләштеләр – килештеләр...

Ничә еллар күрешмәгән дуслар базарда очраша.

– Сәлам, Фәридә! Сине күрер көннәр дә бар икән? Кияүгә чыктың дип ишеттем, дөресме?

– Сәлам, Гөлсинә! Әйе, дөрес. Иностранецка!

– Шулай укмыни? Шәп. Каян таптың андый кешене?

– Бизнесмен ул. Монда эшли. Көтмәгәндә таныштык та, кияүгә дә чыгып куйдым. Хәзер ике бала үстерәбез. Бик матур, тату яшибез.

– Бар бит шундый бәхетле кешеләр дөньяда. Безгә андыйлар туры килмәде. Үзебезнең кешегә кияүгә чыгып, заводта эшлибез икебез дә. Акчасы да күп түгел, бизнесмен булмагач. Алай да, үз фатирыбыз бар. Ә сез коттеджда яшисездер?

– Үз фатирыбыз юк әлегә. Минем әти-әниләрдә торабыз. Ләкин машинабыз бар. Машинасыз булмый аның бизнесында.

– Һе, сез ел саен чит илләргә йөрисездер алай булгач? Кайларда ял иттегез быел?

– Чит илләргә йөреп булмый әлегә. Иремнең эше күп. Үзе генә машинасында. Туган иленә кайтып килә еш кына.

– Син анда булганың бармы? Әти-әнисе ниндирәк кешеләр?

– Ничегрәк дип әйтим икән? Әти-әнисе бар. Тик без таныш түгел. Шулай яхшырак әлегә. Ирем шулай әйтте.

Гөлсинә аптырабрак калып:

– Сиңа шик тудырмадымы андый хәл? Синең йортыңда яшисез, чит илләргә йөртми, әти-әнисе сине белми. Ә үзегез ике бала үстерәсез. Алай да буламы?

– Була, дустым, алай да була...

– Ярый инде, үзеңә андый тормыш ошагач, – дип җавап кайтарды Гөлсинә. – Мин монда иткә килгән идем. Син ничек килеп чыктың? Бизнесмен хатыны булгач, сезгә ризыкны өйгә генә китерәләрдер?

– Юк, мин үзем сатып алырга яратам.

– Сине күрергә бик шат булдым. Уңышлар сиңа, – дип, Гөлсинә үз юлы белән китеп барды.

Ә Фәридә дустының артыннан карап торды да җиләк-җимеш рәтенә атлады. Бизнесмен ире туган ягына товарга кайтып киткәч, җимешләр сату Фәридә өстендә калган иде.

Альбина МОРТАЗИНА

ПЕНСИЯ АЛАМ БЕР БУКЧА

Пенсия алам бер букча,
Күп бирмәгез, дим, юкса
Нишләтергә дә белмим,
Туздырырга җай эзлим.

Әллә дача саласы,
Әллә яхта аласы.
Әллә берәр өлешенә
Сейшелларга барасы.

Буләк итәм, алмыйлар,
Үзебез дә бай, диләр.
Халык йөзә бал-майда,
Яши шунда бер җайга.

Кибетләр тулып ята,
Очсызга товар сата.
Хәерчеләр гүпчем юк,
Пенсиябез чөнки күп.



Абау!

ВӨҖДАН ГАЗАБЫ

Санкт-Петербургта 24 яшьлек мошенник курьер үз теләге белән полициягә бирелгән. Ул аферистлар тарафыннан алданган 86 яшьлек пенсионердан 260 мең сум акча алган. Акчаны клиентларның криптокошелёкларына күчергән, эшләгән өчен үзенә 4 мең калдырган, аннары якындагы полиция бүлегенә киткән. Хокук саклау органнары хезмәткәрләренә егет үзенең вөҗдан газабы белән җәфалануын аңлаткан. Дөресен генә әйткәндә, егет тагын берничә охшаш җинаятьтә катнашуын таныган.

ЯҢАДАН ТУДЫР

Волгоградта яшь әти әти булу авырлыкларына түзә алмаган. Хатынын үз эшләре буенча җибәреп, ул бер айлык кызы белән ялгыз калган. Бала елый башлагач, тынычландыру өчен аңа билгеле булган барлык ысулларны да сынап караган, ләкин аларның берсе дә кычкырып елаган бала өчен туры килмәгән. Өметсезлектән, ир чиктән тыш чаралар күргән – эчкән, ләкин бала кычкыруын дәвам иткән. Аннары әти кызын алып, аны бала тудыру ишек төбендә калдырган. Хатыны бу вакыт эчендә аны кичерер дип өметләнеп, берничә көн өйгә кайтмаска булган. Елак кызны полиция ярдәмендә әнисенә кайтарганнар, ә Тикшерү комитеты гаилә башлыгының тәрбияләү ысулларын тикшерәчәк.


ИПОТЕКА ХОКУКЛАРЫН БОЗУ

Ипотека базарындагы аудит нәтиҗәләренә нигезләнеп, Хисап палатасы иң курыкмаучы ипотека кредиторын билгеләгән. Бер россияле арзан бәядән торак өчен 26 кредит алган. Ул барлык түләүләрне тырышып түләгән. Бу нәтиҗә өстенлекле заем алучылар арасында рекордка әйләнгән. Ләкин белгечләр бу кешенең бурыч коллыгын ипотека кагыйдәләрен бозу дип санаганнар. Мондый кредитлар алып, аларны даими рәвештә кире кайтара алган кешегә дәүләт ярдәме кирәк түгел, дигән нәтиҗәгә килгәннәр.

Ә ПЛАН ЯХШЫ БУЛГАН


Пермь өлкәсендә яшәүче берәү кредитка машина алган. Ләкин түләүне күтәрә алмаган һәм аның якынча 160 мең сум бурычы барлыкка килгән. Эш суд приставларына барып җиткән. Алар бу кешегә бурычларын түләү өчен машинаны суд приставларына бирергә тиешлеген хәбәр иткәннәр. Машинаны озак таба алмагач, бурычлының йорт-җирләрен җентекләп тикшергәннән соң күрше участокта машина кыяфәтенә охшаган бер өем кара туфракка тап булганнар. Туфракны тараткач, суд приставлары югалган машинаны тапканнар.











Анатолий РАДИН


ГАДӘТИ БУЛМАГАН ЫСУЛ

Бүгенге көндә авырып китү – арзан әйбер түгел: республика хастаханәләрендә 1,7 мең табиб җитми. Һәм бу санның төп өлеше авыл җиренә туры килә. Авыл кешеләре бигрәк тә терапевтлар һәм гомуми практика табибларына мохтаҗ. Яшь белгечләрне махсус юлламалар буенча җибәрү дә бу хәлне үзгәртә алмый хәтта. Мәсәлән, район хастаханәләрендә узган ел дәверендә эшләгән 53 табибның 7 се генә үз урынында калган, ә калганнары кире башкала ягына табан ялтыраткан. Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгында бу тискәре тенденцияне гадәти булмаган ысул белән үзгәртергә булганнар. Министр Марсель Миңнуллин җирле хакимиятләргә яшь докторларның шәхси тормышы белән активрак шөгыльләнергә тәкъдим иткән. "Сезнең максат, – дигән ул, – бер ел эчендә аларны... район кызларына өйләндерергә кирәк. Хәләл җефетләре һәм балалары барлыкка килгәч, яшь белгечләр зур шәһәрләрнең утларына карап ямансуламый башлаячак, имеш. Ысул тормышка ашырыла башлаган һәм якын вакытта авыл халкының массакүләм рәвештә сәламәтләнә башлавын көтәргә була.

Людмила САФИУЛЛИНА



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Рәфкать ИБРАҺИМОВ

БУЛМЫЙ ИКӘН БУЛМАГАЧ

Миңа еш кына Коръән ашларына йөрергә туры килә. Мондый мәҗлесләргә күбесенчә олы яшьтәге кешеләр килсә дә, алар үз халкының үткән тарихын да, хәзергесен дә белмиләр кебек күренә. Мәчетләрдән килгән хәзрәт яки абыстайлар вәгазьләрен матур итеп сөйли, ләкин алар да безнең милләтебезнең хәзерге вакытта нинди кысаларда яшәгәнен белми шикелле. Динебезне тотарга рөхсәт иткән җитәкчеләргә рәхмәт әйтергә онытмасалар да, безне телсез калдыру өчен кабул ителгән кануннардан алар бихәбәр булып күренә. Ул вәгазьләрдә балаларыбызга ана телен өйрәтү кирәклеге сөйләнми. Бу, бәлки, бөтен җирдә дә алай түгелдер, мин үзем ишеткәннәрне генә язам.

Минем язган мәкаләләремне дә кызыксынып укып карамыйлар. Саба, Балтач, Арча якларындагы бик якын булмаган туганнарым гына укыдык, дип, шалтыратып әйтеп торалар. Ят каналлардан ялган сөйләүчеләргә ышанып, алар үзләрен бик күп белүчеләр итеп, үзләренең "укымышлы наданлыкларын" исбатлый да башлыйлар әле. Бу мәҗлестә утырганда да бүгенге көндә барган вакыйгаларга битараф сөйләүчеләр булды. Егермедән артык кеше арасында телебезне яклап сүзгә катнашучы булмады. Ә без телебезне саклап калу өчен тырышып йөргән булабыз.

Соңгы өч аш мәҗлесендә мәчеттән килгән хәзрәтләр дә тел, милләтебезнең хәле турында сөйләшеп утыруны өнәп бетермәделәр. Берсе, бездә 200 милләт бар, аларның барысын да саклап калып буламыни, дигән иде. Ул милләтләрнең үз дәүләтләре булмаган да, әле дә юк. Безнең үз дәүләтчелегебез булган. Конституциядә язылганча, әле дә үз дәүләтебез бар. Телебез дә дәүләт теле булып санала. Илдәге халык саны буенча да икенче урында торабыз әлегә. Мәчетләрдәге хәзрәтләрне дә тел мәсьәләсе кызыксындырмый икән. Алар, бездә бар да ал да гөл, дип яшиләр бугай.

Элек булган аш мәҗлесендә Левченко бистәсеннән килгән кап-кара озын сакаллы хәзрәт вәгазьләрен урысча укыды. Югыйсә анда бер генә рус кешесе дә юк иде. Хәзер монысы тыелды бугай инде. Икенче бер хәзрәткә шул турыда әйткәч, бездә толерантлык, алар безне хөрмәт итсен өчен шулай кирәк, дигән әкият сөйли башлады.

Мәчеткә йөрүчеләрне телгә караганда, ашларга йөреп, сәдака җыю күбрәк кызыксындыра кебек тоелды. Мәчеттән килгән хәзрәткә бер кат сәдакалар биреп чыккач, ул: "Тагын бирүчеләр булса, бирегез, мин акчаларны мәчеткә алып кайтып тапшырам", – дигәч, кешеләр тагын акча янчыкларын актара башлады. Бирергә тиешле кешеләр үзләре белеп биргән бит инде. Сәдаканы сорап алмыйлар дигән булалар тагын.

Без телебезне саклап калуда мәчетләргә зур өмет белән карыйбыз да бит, монда да бар да ал да гөл генә түгел килеп чыга икән әле.



Пётр НОВИЧКОВ, 1953 ел.

Израиль – АКШ кулындагы марионетка.



Эрнст ГЕЛЬМС, 1963 ел.

– Бу минем тынычлык "күгәрченем".



• • •

– Доктор, минем башымда гел ниндидер тавышлар...

– Ә наушникларны колагыгыздан алып карамадыгызмы?

• • •

Циркта. Аренага куәтле көрәшче чыга да, кулына лимон алып, стакан тутырып согын сыга. Һәм сорый:

– Тамашачылар арасыннан кем дә булса чыгып, бу номерны кабатлыйсы киләме? – ди.

Уртага ябык кына ир кеше чыга, теге сыгып бетергән лимонны ала да шуннан тагын ике стакан сок сыга. Көрәшче гаҗәпкә калып:

– Сез кем?! Кайдан?!

– Салым инспекциясеннән мин, – ди.

• • •

Безнең яшәешнең мәгънәсен менә бу игълан бик ачык аңлата: "Гардеробта калган кыйммәтле әйберләрегез һәм акчаларыгыз өчен администрация җаваплылык алмый. Номерокны югалткан очракта – 1000 сум штраф".

• • •

Бер бабай эскәмиядә утырган да елый.

– Нигә елыйсың, бабакай? – дип сорыйлар моннан.

– Менә яшь кызга өйләнгән идем. Иртән торганда – ятагыма коймак китерә, көндез пирожкилар белән сыйлый, кич белән массаж ясый, ә йокларга яткач, төне буе миннән ялына...

– Ә нигә елыйсың соң?

– Менә, улым, кайда яшәгәнемне оныттым...

• • •

– Начальствоны күз белән ашарга кирәк, ләкин тончыга күрмәгез!

• • •

– Артык мигрантлардан ничек котылырга?

– Япониядәгечә. Эш бирүчеләрне үзебезнекеләргә боларга караганда күбрәк түләргә мәҗбүр итүче закон кабул итәргә кирәк...

• • •

Хөкүмәт Googleны "өшетмәкче". Кеше сәламәтлеге өчен кайгырту бөтенләй юк. Сырхауханәләрдә болай да инде кыргый чиратлар, врач диагнозны ачыклаганчы, компьютер эшләп китеп, коридорда кеше тыгынынннан үтеп өйрешле түгел.











ЧИТКӘ КАГАЛАР

Кадерле "Чаян". Бөтен республика буенча "Безнең ишегалды" программасы гүли. Телевидениедәге байтак тапшыруларда төзекләндерелгән матур, уңайлы ишегаллары һәм урамнар күрсәтелеп, мактанып алулар җемелдәп куя. Нишләп менә шундый гаҗәеп кирәкле эшләр безнең бистәне әйләнеп уза икән?

Брикетныйда берничә номерланган аллея бар, шуларның ахырында – Кадышев-11 һәм Кадышев-12 урамнары. Менә шушы урамнар өчен нигәдер финанслау җитми. Кайчандыр безгә газ килеп җитмәде, урамны яктыртулар, су үткәрү, ә күптән түгел бистәбездә юлларны асфальтлау эшенә керештеләр. Әлеге дә баягы гадәт буенча, бу гамәл дә 11 нче, 12 нче аллеяларга җиткәнче туктады. Нәтиҗәдә, әйбәтләп түшәлгән юлдан 20 ләп йорт мәхрүм калды. Җәен тагын тузанга күмелербез инде, язын һәм көзен – саз ерырбыз. Җирле хакимияттән юньле аңлатма көтеп булмас. Бәлки "өстә" берәр әйбәт кеше табылыр?..

Брикетный бистәсендә яшәүчеләр

КАЗАН

МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ – МОГҖИЗА!

Хөрмәтле редакция! Матур инде мәктәп еллары. Без аны һәрвакыт сагынып искә төшерәбез. Ә менә безнең балаларыбыз аны ничек искә алыр?

Ике дистә елга якын без үзебезнең мәктәбебез булыр дип өмет итәбез. Казанның генпланы буенча, ул күптән төзелергә тиеш иде инде, ләкин һаман төзелмәде. Менә шуннан бирле балаларыбызны шәһәрнең якындагы белем бирү оешмаларына интегеп йөртәбез. Дәресләргә барып җитешү өчен малай-кызларыбызга һәм аларның әти-әниләренә иртәнге биштә торырга, аннан соң теләсә нинди һава торышы булуына карамастан, километр ярым үтеп, якындагы тукталышка барырга кирәк. Җитмәсә, "бөке"ләр... Төрле түгәрәкләргә, секцияләргә йөрү турында уйлыйсы да юк. Анда йөреп, ничек итеп өйгә кайтып җитәсе. Шулай булгач, мәктәптә уку вакытларын ничек күңелле итеп искә төшерәсең!

Берничә еллар элек укучыларыбызның әти-әниләре аптырап кар өстенә "мәктәп" дип язып, интернетка рәсемен төшереп тә җибәрделәр. Хәтта шундый "кино" да түрәләрнең күзен чылатмады, төзелешкә акча бүлену мәсьәләсен дә кузгатмады. Хәер, хәзер кайда мәктәп бинасы булачагы билгеләнде бугай. Күпме бала укыйсын да санадылар кебек, әмма кайчан төзеләчәген берәү дә әйтмәде. Яңа уку елы искечә башланды – тукталышларда. Шул вакыт эчендә бистәбез яңа комплекслар һәм коттеджлар белән тулыланды. Балалар да күбәйде. Инде курка калдык, тагын ике елдан ул хәтле балага бер генә мәктәп җитмәс...

Вишнёвка һәм Привольный бистәсендә яшәүче әти-әниләр.

КАЗАН





Шәрәф Мөдәррис 1919 елның 1 ноябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне үз авылында ала, җидееллык мәктәпне күрше Мунчәли авылында тәмамлый һәм 1935 елда Казанга килеп, педагогика институты каршындагы рабфакка укырга керә. Аннары ике еллык укытучылар институтында укый. 1933 елдан ук шигырьләре белән матбугатта күренә башлаган Шәрәф Мөдәррис студентлык чорында аеруча дәртләнеп иҗат итә. 1937 елда ук инде «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Шагыйрьнең әдәби тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дә шушы чорда башлана. 1941 елда аның тәрҗемәсендә чуаш әдәбияты классигы Константин Ивановның атаклы «Нарспи» поэмасы басылып чыга.

1941 елда Шәрәф Мөдәррис Кызыл Армия сафына алына. Шул ук елның җәендә Смоленск өлкәсендә барган канлы сугышларның берсендә яраланып, контузия ала һәм Мәскәү госпиталенә озатыла, аннан сәламәтлеген ныгыту өчен Казанга һәм туган авылына кайта. 1942 елда ул яңадан сугышка китә, минометчы-солдат булып Төньяк-Көнбатыш фронтында сугыша, шул ук фронтта татар телендә чыга торган «Ватан өчен» газета редакциясендә хәрби мөхбир булып хезмәт итә. 1944–1945 елларда Шәрәф Мөдәррис бу эшен «Җиңү байрагы», «Фронт хакыйкате» исемле фронт газеталарында дәвам иттерә. Мөдәрриснең бу чор поэтик иҗатының да төп эчтәлеген тәшкил итә. Армиядән кайткач, төрле газета редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1956 елда ул Максим Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый.

Әдип зур күләмле поэмалар, шигъри повестьлар яза, лирик һәм публицистик шигырьләр, юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр һәм памфлетлар иҗат итә, матбугатта халыкара темаларга үткен эчтәлекле мәкаләләр бастыра. Татар поэзиясендә беренчеләрдән булып, ул сонет жанрына юл ача, аның матур үрнәкләрен язып күрсәтә. Шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли.

Шәрәф Мөдәррис шигъри талантының ачылып җиткән чорында, 1963 елның 28 апрелендә вафат була.

ЯКТЫ ХАТИРӘ

Киндер күлмәк иде өстемдә,
Ертык капчык иде аркамда, –
Килеп төштем таңгы Казанга,
Ярты шәһәр йоклап ятканда.
Минем тугыз йөз утыз бишенче...
Сентябрьнең тәүге атнасы...
Басулардан килгән малайга
Казан, Казан, ишек ачсачы!
Ташлаттырып авылым җылысын,
Суырып кына алыр, ахрысы...
...Витринада, гәзит өстендә
Уйнап тора кояш яктысы...
Акрын гына киләм, төбәләм,
«Татарстан», соңгы саныңа,
Фатих Хөсни язган мәкаләң
Кинәт шунда күзгә чалына.
Нидер сукты кинәт йөрәккә,
Китә яздым шунда егылып:
Чагылдырды күзне яктылык,
Килеп бәрде җанга җылылык!
«Татарстан» мине сәламли.
Карыйм кабат, укыйм яңадан.
Шушы таңда нурлы Казанда
Кабат тудым төсле анадан.
Укыйм тагын: «Нәни җырчылар».
Бәреп тора күзгә исемем...
Куеп шулай мактау канатын,
Ачтың миңа, Казан, ишегең!
Кояш нуры – гәзит битендә,
Гәзит нуры – минем исемдә.
Ертык капчык иде аркамда,
Киндер күлмәк иде өстемдә...

АЙДАГЫ ЗӨҺРӘ

Көянтәңне асып, ялгыз
Моңайдың һаман:
– Насыйп микән, кайтып, илем
Бер күрер заман!
Кайтырсың, Зөһрә, кайтырсың
Борчылып ятма!
Җирдән Айга салдык менә
Беренче басма.
Сөйгән ярың сәлам бирде
Син нечкә билгә;
Чиләкләрең шылтыратып
Төшәрсең Җиргә.
Кайтырсың, Зөһрә, кайтырсың,
Тик билет юнәт.
Син киткәч тә Айда калыр
Бүтән бер сурәт!

ТУКАЙ

Әй Тукай, ил һәм гасырда
ялкының янган Тукай;
Ай-кояштан, хөррияттән
яктылык алган Тукай!
Шигъриятең турылардан
турырак бер юл табып,
Караңгы төн караңгысын
яшендәй ярган Тукай!
Булып әнкәң – иркен ватан,
бәхеткә хаклы ватан, –
Шунда шифаң, таңгы чыгың,
яңгырың яуган Тукай!
Үлмәгән, тик горур очкан
мәһабәт лачын сыман,
Бер минутка тауга кунып,
канатын япкан Тукай!
Ил белән бергә үлемсез,
яшәүчән бер ир булып,
Тик ял иткән, йокымсырап,
уйланып яткан Тукай!
Үлемсезлек, бөеклекнең
ачкычын алган Тукай,
Әй Тукай, ил һәм гасырда
ялкының янган Тукай!

ГАШЫЙК КАРТКА

Илле яшьтән уздың, тик һаман да
«Кыз», «кыз» диеп шигырь язасың;
«Чәчең, күзең, кашың гүзәл» дисең,
Гыйшык тотып, һаман азасың.
«Кыз», «кыз» диеп һаман,
тешең кысып
Көлдерәсең инде улыңны!
Әнкәсенә кайчан багышладың
Ичмасам бер шигырь юлыңны?
Үләрсең син, ахры, «гыж», «гыж» диеп.
Кызда булгач һаман хыялың.
«Хатыным» дип язсаң, шигъриятькә
Тиярмени берәр зыяның?
Ерактагы алсу алмаларга
Нигә, җаным, күзең алдана?
Син шигырь яз үзең көн дә, көн дә
Күрә торган гади алмаңа!
Күзең төбәп ерак йолдызларга,
Җыр тезәсең дөньяң онытып.
Үзең тордың хатын учагында
Гомер буе кулың җылытып.
Автоматың әлегә төзек икән,
Соңгы караң багла тик аңа!
«Кыз», «кыз» диеп һаман тилергәнче,
«Хатыным» дип яз соң, дивана!

СИН, БОЛАЙ, БЕЛДЕКЛЕ...

Син, болай, белдекле. Хәреф таныйсың.
Аңлыйсың беркадәр «сатира» сүзен, –
Күзлегең өстеннән залга карыйсың,
Чәйнисең лыгырдап, сафсата чүбен.
Алдыңда тау кадәр тезислар тотып,
Сөйлисең ялкынлы, сугышчан нотык:
– Ух, безгә шулчаклы сатира кирәк,
һәм кирәк, шулай ук, һәммәсе, димәк!
Кайтасың. Чыгышың «шәп» бәя алган.
– Сөйләдем, – дисең син, – фикер кузгатып.
Рәсемнән Гогольне күреп шул вакыт,
Куркасың, шүрлисең, качасың аннан.
һәм бик еш син, куян, буласың көлке,
Йөргәндә алдыңда сатирик керпе.



Дамир ГАРИФУЛЛИН

ШАГЫЙРЬЛӘР ШӘҖӘРӘСЕ

Разил Вәлиев, Хәйдәр Гайнетдин, Зөлфәт Хәким, Рафис Сәлимҗанов...

Һәммәсе дә бер шәҗәрәдән дисәм, ышанмаучылар да булыр, мөгаен. Бер нәсел-нәсәптән шулкадәр шагыйрь чыгамыни диярләр. Ә менә чыга икән шул.

Түбән Кама районындагы Шәнгәлче авылында гомер сөргән Йосыф бабайның нәселен дәвам итүчеләр алар.

Шагыйрь Кол Галинең мәшһүр кыйссасының төп герое исемен йөрткән Йосыфның балалары дистәдән артып киткән. Исән үскәннәре Зәйнулла, Хәбибулла, Хәмит, Сәгыйть, Габдулла исемле булганнар.

Зәйнулла дигәне Зөлфәт Хәкимнең дәү бабасы була. Аның улы Хәкимханнан килә Зөлфәтнең фамилиясе. Хәкимханның уллары Заһит һәм Зөфәр исемлеләр. Зөфәрнең Зөлфәт һәм Исфира исемле балалары бар. Зөлфәте шул җырчы да, драматург та, язучы да булган Зөлфәт Хәким була да инде. Исфирасы җырчы Рафаэль Сәхабиевның энесе Равилдә кияүдә. Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтик: Рафаэль Сәхабиев шулай ук Шәнгәлче авылында туып-үскән. Бабасы Сәхабетдин исемле. Шуннан Сәхабиев фамилиясе килә. Сүзебез Йосыф бабай шәҗәрәсе турында иде. Аның Хәбибулла исемле улының Туйчы исемле улы була. Туйчының Бибиҗамал исемле кызы Дүртмунча Гайнетдин Зәйнулла улы белән тормыш кора. Бу никахтан Гайфетдин исемле улы туа. Гайфетдин исә җырчы Илһам Шакировның апасы Гыйльмисафага өйләнә. Бу гаиләдә 1952 елның 27 ноябрендә булачак шагыйрь Хәйдәр дөньяга килә. Ул 2000 елның 24 июнендә, фаҗигагә уралып, арабыздан китеп барды.

Йосыф бабайның Хәмит исемле улы да булган дигән идек. Аның да гомере Шәнгәлчедә үтә. Хәмит бабай хатыны үлгәндә 60 яшендә була. Ул 17 яшьлек кызны хатынлыкка ала. Болары сүз уңаенда гына. Аның Гөлфания исемле төпчек кызының кызы Гайшә исемле. Бу Гайшә – шагыйрь Рафис Сәлимҗановның анасы.

Татарстан халык депутаты, озак еллар республикабызның Милли китапханәсе директоры булып эшләгән шагыйрь Разил Вәлиев Ташлыкта туган. Әтисе ягыннан бөтен нәселе Ташлыкныкылар.

Әнисе, әнисенең әнисе ягыннан караганда Разил Вәлиев шәҗәрәсе без телгә алган Шәнгәлченең Йосыф бабай нәселеннән килә. Зөлфәт Хәкимнең дәү бабасы Зәйнулланың Хәбибә исемле кызы (1888 елгы) Ташлык авылының Нуретдин Хөснетдин улына кияүгә чыга. Аларның бер кызы Таһирә исемле була. Менә шул Таһирә Кадермәтнекеләрдән Исмәгыйль исемле кешегә кияүгә чыга. Шушы гаиләдә 1947 елның 4 гыйнварында Разил туа.

Рәфкать ШАКИЕВ

КЫЙБЛА

Кыйбла – базар, иман – бизнес,
Табынабыз акчага.
Берәүнең дә исе китми,
Сулар үргә акса да.

Бернәрсә дә гаҗәп түгел,
Бар гамәлебез ялган.
Аллаһ урынына хәзер
Акча йөри иң алдан.

Бүген акча бик тәтеми,
Бил бөгеп тә, тир түгеп.
Кыйбла – базар, без – сәҗдәдә,
Багынабыз тез чүгеп.

Бизнеска бәйле тынычлык,
Илләр ала ил үчен.
Бәхет өчен туабыз да,
Үләбез акча өчен.

Иршат ГАРИФУЛЛИН

ӨЛКӘННӘР ЗАРЫ

Күзләр килүгә, гомер чиге җиткәч,
Без – карт-корыга бәйрәм ясыйлар.
Зоопаркларга бушлай кереп була,
Күтеп торачак сине музейлар.

Очрашулар бик күп, концертлар да,
Өлгер генә кайсысын сайларга.
Экскурсияләргә рәхим итегез,
Күтәләр сине әллә кайларда.

Менә декада бетә, лафа кими,
Тормыш кайта үзенең көенә.
Бар олылар тагын уйлый башлыйлар
Күпмегә артыр диеп пенсия.

Кемнең пенсиясе болай да бик зур –
Аларныкы артачак байтакка.
Аз пенсия алганныкы җитми дә
Сөт һәм ипи, дарулар алмакка.



Николай ВОРОНЦОВ


ЧАЯН
САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 11 (1948) ноябрь 2024
Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.11.2024 ел.
Тираж – 1925 Заказ А-2517
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
16+
Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!

ЖЫРЧЫ РАЗИЯ ...
ХАЛЫК ЖЫРЫ "... КАРТ"
"... АЙ, ТУЗ БАШЛЫ"
КӨЧ- (-1)...
"..., КАРАП ТОРУЛАРЫ"
АТАКЛЫ ФУТБОЛЧЫ
ШАГЫЙРЬ ... КАСЫЙМОВ
КЫЛЛЫ ИНСТРУМЕНТ
"АЛТЫН ..."
ОЧЧЫ
УКСУС
КАМЫР ЖӘЮ ЖАЙЛАН-МАСЫ
НӘСӘП
ТӨССЕЗ БУЯУ (-1)
"... СУ"
"ТУГАН ..."
... БЕЛӘН СУ ТАШУ
ЮК-...
«... ЧУКЛАР, ДИМ-ДИМ»
ДӘҮ ӘТИ
ШАГЫЙРЬ ... ЗӘЙДУЛЛА
ИНО-МАРКА
«СУТЫЙ»
... ҺӘМ ЧҮКЕЧ
СОЮЗ
...ЛЕ БАЛ
"БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"
КУХНЯ ЖИҺАЗЫ
"... ИКЕ БЕЛӘГЕМ"
ЧАБЫШ АТЫ
СЫЙФАТСЫЗ ТОВАР
ИСКЕ ГАДӘТ
...ЛЫ ТӨН
"...ЫМ ЖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА"
"... ТӨШКӘНДӘ"
"УРАКЧЫ ..."
"... ЮЛНЫҢ ТУЗАНЫ"
ТЫНЛЫ МУЗЫКА КОРАЛЫ(-1)
"... КАЕН"
КЕЧЕ ПЛАНЕТА
ШАХМАТТА ЖИҢҮ

16 11 4 12 2 6 10 3 15 14 7 8 1 9 5 13

Фәхри ...

... Ильясов



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Кем ул олигарх?

2. Акча ике тапкыр күбрәк булсын өчен нишләргә кирәк?

3. Йөзең белән пычракка егылсаң нишләргә?

4. Картлыкның төп байлыгы?

5. Әгәр дә ир-атлар хатын-кызның уй-фикерен укый алырга өйрәнсә нәрсә булыр иде?

6. Барысының да яшәү минимумын күтәрер өчен нәрсә эшләргә кирәк?

7. Яшәүнең максаты 90-60-90 булуы дөресме?

ЖАВАПЛАР

1. Зур санлы кеше. 2. Аларны көзге каршына куярга кирәк. 3. Торып бас та, аның дәвалау өчен файдасы булуын ышандыр! 4. Истәлекләр. 5. Алар анда барыбер бернәрсә дә аңлый алмаслар иде. 6. Баен чергәненнән максимумын киметергә. 7. Юк. Яшәештә иң төп максат – 120/80.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 10 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«СИН ГОМЕР АГЫШЛАРЫМ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. ИЛДАРОВА (Биектау),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Биектаудан **Галия ИЛДАРОВА!**




Сергей КОКАРЕВ



Александр ШУЛЬПИНОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Валентин ДУБИНИН





